Быелнын беренче оч аенда Россиядә яшәvче һәр ике кешенен берсенә (43 процент) мошенниклар шалтыраткан. «Лаборатория Касперского» белгечләре әнә шундый нәтижәгә килгән. Шул вакыт эчендә мошенниклар ил халкынын 80 миллиард сум акчасын урлаган. Россиядә яшәvчеләр кырыгалдарлар кулына кон саен 40 миллион сум чамасы акча кvчерә, дип кисәтә хокук сакчылары.      Әле генә Мордовиядә остәмә белем бирv 61 яшьлек педагогын мессенджерда vзен финанс учреждениесе хезмәткәре дип таныштырган билгесез хатын, банктагы счетыннан акча алырга тырышуларына ышандыра һәм янәсе куркынычсыз счетларга кvчерергә кинәш иткән. Зыян кvрvче 1 миллион сумнан артык акчасын алган һәм шәһәр банкларынын берсендә урнашкан банкоматка юнәлгән. Ә алдакчылар хатын белән элемтәне бер минутка да озмәгәннәр. Банк хезмәткәрләре хатын-кызнын кулында зур сумма акча булуын сизәләр һәм гражданкадан ул vз теләге белән акча кvчерәме дип кызыксыналар. Зыян кvрvче ярдәмнән баш тарта һәм операцияне дәвам иттерә. Нәтижәдә ул мошенникларга 343 мен сум кvчергән. Калган сумманы банк хезмәткәрләре сакларга ярдәм иткәннәр: операцияне шикле дип санап, акча кvчерvне чикләгәннәр.
Балалар арасында да мошенник корбаннары шактый. Кибераналитик-лар жәйге каникул чорында мәктәп балалары арасында мошенник корбаннары бермә-бер артырга момкин, дип кисәтә. Ялга да, телефонда утырырга да вакыт кvбәя бит.
Сонгы арада инвестиция ярдәмендә акча эшләргә теләп топ башына утыручылар да арткан. Мошенниклар тиз арада кvп итеп акча эшләп алырга тәкъдим итә, корбанынын хис-кичерешләре белән уйный, аек акылга ботенләй урын калдырмый. Мошенникны кvрсәтә торган ин беренче һәм топ билгеләрнен берсе бу. Чын инвестиция белән эш иткәндә эшләр алай жинел генә бармый, анда һәрвакыт риск бар. Мошенниклар еш кына «бу тәкъдим бары сезнен очен генә», «нибары биш урын калды», «бу бердәнбер һәм сонгы момкинлек» ише сvзләр куллана. Чынлыкта инвестициягә бәйле тәкъдимнәрне алай таратмыйлар.
Сvз унаеннан, мошенниклар халыкны алдау ысулларын гына тvгел, алдаганда мошенник кулланган сvзләрне дә vзгәртеп тора. Сонгы арада алар «куркынычсыз счет» дигән сvз урынына «остәмә счет», «криптовалюталы счет», «декларация счеты» ише сvзләр куллана башлаганнар. Шушы дvрт сvзнен берсен булса да ишетсән, сойләшvне шундук озәргә кирәк, дип кисәтә хокук сакчылары. Алданган очракта «02» яки «112» номерларына шалтыратып, полициягә хәбәр итегез.